**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 99пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләрнең күпләп була торган урыннары исемлеген раслау турында»2015 елның 1 июлендәге 186пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген төгәлләштерү һәм төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләрнең һәм объектларның (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы саклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортлары рәвешләрен раслау турында» 2015 елның 6 мартындагы 272 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Спорт объектларының террорчылыкка каршы якланганлыгына таләпләрне һәм спорт объектларының куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында»2015 елның 6 мартындагы 202 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актлары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында» 2015 елның 1 июлендәге 186пи номерлы карарына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма

комитетының 2016 елның 28 мартындагы 42пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлегендә 3 һәм 33 пунктларны төшереп калдырырга; ;

б) 4-32 пунктларны 3-31 пунктлары дип санарга;

в) 34-36 пунктларны 32-34 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин